КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 сентябрь г.Казань № 1045

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 11 ноябрь, 866 нчы; 2014 ел, 8 май, 304 нче; 2014 ел, 17 май, 330 нчы; 2014 ел, 26 декабрь, 1032 нче; 2016 ел, 17 февраль, 98 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 733 нче; 2018 ел, 20 март, 159 нчы; 2019 ел, 8 апрель, 274 нче; 2019 ел, 21 май, 427 нче; 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 985 нче; 2019 ел, 24 декабрь, 1186 нчы; 2020 ел, 25 февраль, 140 нчы; 2020 ел, 1 апрель, 248 нче; 2020 ел, 27 май, 428 нче; 2022 ел, 31 март, 295 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты составында:

оештыру комитеты составыннан Р.Р.Сираҗиевны чыгарырга;

оештыру комитеты составына Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары Юлай Рим улы Миңнуллинны кертергә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибендә:

4.8 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

5.5.1 пунктта:

беренче абзацта «5.5.1.» саннарын «$5.5^{1}$.» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле «в» пунктча өстәргә:

«в) бу Тәртипнең 3 нче кушымтасында бирелгән форма нигезендә Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре тарафыннан башка бюджетара трансферт җибәрелергә планлаштырыла торган, Министрлык белән килештерелгән чаралар исемлеге булу.»;

түбәндәге эчтәлекле $5.5^{2}$ пункт өстәргә:

«$5.5^{2}$. Башка бюджетара трансфертны тотырга рөхсәт ителә торган чаралар исемлеге:

социаль әһәмиятле объектларда төзелеш-монтаж һәм ремонт эшләре (авыл мәдәният йортлары, һәйкәлләр, күперләр һ.б.);

авыл хуҗалыгы техникасы (трактор, кардан чистарту машинасы һ.б.) сатып алу;

юл-урам челтәрен ремонтлау (вак таш салу, чокырларны ремонтлау) һәм тротуарлар салу;

ял итү урыннарын төзекләндерү (парк, сквер, чишмә һәм башкалар (агачлар кисү, үлән чабу, агач тамырларын казып чыгарудан башка));

зиратларны төзекләндерү (коймалар тоту, чүп савытлары кую һ.б.);

балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары сатып алу һәм урнаштыру;

сууткәргеч челтәрләрен төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау;

урам яктырткычларын урнаштыру һәм ремонтлау.»;

түбәндәге эчтәлекле $5.5^{3}$ пункт өстәргә:

«$5.5^{3}$. Башка бюджетара трансфертны тоту тыелган чаралар исемлеге:

административ биналарны ремонтлау;

администрацияләр биналары өчен җиһаз сатып алу;

үлән чабу, агач кисү, агач тамырларын казып чыгару;

кардан чистарту;

техника (компьютер, принтер, фототехника, музыкаль җиһаз һ.б.) сатып алу;

канцелярия товарлары сатып алу;

костюмнар, кием-салымнар, пәрдәләр, портьер һ.б. тегү;

ягулык сатып алу;

гражданлык җаваплылыгын иминләштерү.»;

5.6 пунктта:

беренче абзацта «Министрлык тарафыннан расланган форма нигезендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә» сүзләрен «бирү нәтиҗәләренә» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләрен «башка бюджетара трансферт акчасы исәбеннән чыгымнар турында хисап һәм башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

5.6.1 пунктта «5.6.1.» саннарын – «5.6$^1$.» саннарына, «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече» сүзләрен «бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5.6$^2$ һәм 5.6$^3$ пунктлар өстәргә:

«5.6$^2$. Башкарма комитет бу Тәртипнең 3 нче кушымтасында бирелгән форма нигезендә Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре тарафыннан башка бюджетара трансферт җибәрелергә планлаштырыла торган чаралар исемлеге проектын (алга таба – исемлек проекты) Министрлыкка килештерүгә җибәрә.

Министрлык исемлек проекты кергән көннән 10 эш көненнән артмаган срок эчендә әлеге проектны килештерү турында йә килештерүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турында башкарма комитетка хәбәр итә.

5.6$^3$. Башкарма комитет Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре тарафыннан башка бюджетара трансферт җибәрелергә планлаштырыла торган чаралар исемлегенә үзгәрешләр кертү өчен Министрлыкка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Министрлык башкарма комитетның мөрәҗәгате кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 20 көн эчендә Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре тарафыннан башка бюджетара трансферт җибәрелергә планлаштырыла торган чаралар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында яки үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Килешүгә бу пунктта каралган үзгәрешләрне кертү яклар тарафыннан өстәмә килешү төзү юлы белән гамәлгә ашырыла. Өстәмә килешү Килешүнең аерылгысыз бер өлеше булып тора һәм аңа кул куелган көннән үз көченә керә.»;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Башкарма комитет Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча башка бюджетара трансферт акчасы исәбеннән чыгымнар турында хисап. Әлеге хисап квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 7сеннән дә соңга калмыйча тапшырыла;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү һәм аларны ирешү максатларында кабул

ителгән йөкләмәләр турында хисап. Әлеге хисап хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча тапшырыла;

бу Тәртипнең 4 нче кушымтасында бирелгән форма буенча Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсында җиңүче тарафыннан башка бюджетара трансфертның файдаланылуы турында финанс хисабы. Әлеге хисап хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартыннан да соңга калмыйча тапшырыла;

килешүдә каралган срокларда һәм формалар буенча өстәмә хисаплылык (килешүдә шулай билгеләнгән очракта).»;

түбәндәге эчтәлекле 5.8[1] пункт өстәргә:

«5.8[1]. Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсында җиңүче тарафыннан башка бюджетара трансфертның файдаланылуы турында финанс хисабына бирелә торган документлар исемлеге:

аукцион йомгакларын үткәрү беркетмәсе (расланган күчермәсе);

муниципаль контракт (расланган күчермәсе);

сатып алу-алу, хезмәтләр күрсәтү шартнамәсе (расланган күчермәсе);

локаль ресурс смета исәп-хисабы (расланган күчермәсе);

төяп җибәрелгән товарларның, күрсәтелгән хезмәтләрнең счет-фактурасы (расланган күчермәсе);

төяп җибәрелгән товарлар, күрсәтелгән хезмәтләр өчен түләүгә счет (расланган күчермәсе);

төяп җибәрелгән товарларга товар накладное (расланган күчермәсе);

универсаль тапшыру документы (расланган күчермәсе);

туры килү сертификаты (расланган күчермәсе);

башкарылган эшләрнең кыйммәте турында белешмә кәгазе (расланган күчермәсе);

башкарылган эшләр акты (расланган күчермәсе);

банкларның түләү йөкләмәсе (финанс-бюджет палатасы мөһере белән);

эшләр башланганга кадәр, эшләр үткәрелгән вакытта һәм эшләр үткәрелгәннән соң һәр чараның төрле ракурсларда төшерелгән фотосурәтләре.

Сатып алынган техникага түбәндәгеләрне өстәмә тапшырырга кирәк:

паспорт (расланган күчермәсе);

гарантия талоны (расланган күчермәсе);

кабул итү-тапшыру акты (расланган күчермәсе);

теркәү турында таныклык (расланган күчермәсе);

техник тикшерүне узу турында таныклык (расланган күчермәсе);

транспорт чарасын Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлеге (шәһәр җирлеге) балансына кую турында боерык (расланган күчермәсе);

сатып алынган техниканың фотосурәтләре (шул исәптән номер билгеләре белән).»;

5.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.11. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары һәм башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләренә ирешү йөкләмәләре бозылган очракта, тиешле акча Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.»;

әлеге Тәртипкә 3 һәм 4 нче кушымталарны (карарга теркәләләр) өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибенә 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 сентябрь, 1045 нче карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре тарафыннан 202__ елның башка бюджетара трансферты җибәрелергә планлаштырыла торган чаралар исемлеге

| Т/с | Татарстан Республикасы авыл җирлеге / муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге | Чаралар исеме | Башка бюджетара трансфертны тоту юнәлеше |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| … | | | |

Татарстан Республикасы
икътисад министры урынбасары

__________/___________________________
(имзасы)  (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе:

_____________/_____________________________
(имзасы)  (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

____________________________________

Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибенә 4 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 29 сентябрь, 1045 нчы
карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсында җиңүче тарафыннан башка бюджетара трансфертның файдаланылуы турында
финанс хисабы

Бу Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсында җиңүче тарафыннан башка бюджетара трансфертның файдаланылуы турындагы финанс хисабы белән (алга таба – хисап) Татарстан Республикасы авыл җирлегенә һәм муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегенә башка бюджетара трансферт бирү турында ____________ ___________ номерлы килешү нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертны җирлектәге тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү объектларының матди-техник базасын ныгытуга, социаль инфраструктура объектлары төзүгә һәм җирлекне тышкы яктан төзекләндерүгә һәм җирлекнең башка социаль әһәмиятле мәсьәләләрен хәл итүгә тотуны раслыйм.

| Үткәрү срогын, урынын һәм анда катнашучыларны (аның башкаручыларын) күрсәтеп, чаралар, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр исемнәре | Чаралар үткәрүне, эшләр башкаруны яки хезмәтләр күрсәтүне раслый торган документлар исеме һәм реквизитлары | Барысы, сум |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| Барлыгы | | |

Хисапка Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибенең $5.8^{1}$ пунктында күрсәтелгән исемлек нигезендә бу хисап мәгълүматларын дәлилли торган документларның расланган күчермәләре тиешле рәвештә ___ биттә ______ нөсхәдә теркәлә.

Татарстан Республикасы
икътисад министры урынбасары

__________/__________________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе:

_____________/_________________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

________________________________________